**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**14.12.2018** **№195**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтен башкарган затларның эш тәртипләренә карата булган таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр бәрелеше, низагларны хәл итү буенча комиссия турында нигезләмәне раслау турында

2004 елның 27нче июлендәге 79нчы номерлы ФК «Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәте турында” дип исемләнгән Федераль канун нигезендә, 2008 елның 25 декабрендәге 273 номерлы ФК «Ришвәтчелеккә каршылык турында” дип исемләнгән Федераль канун, 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы «Федераль дәүләт хезмәтендә булган затларга карата булган таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр бәрелеше, низагларны хәл итү буенча комиссияләр турында” дип исемләнгән Россия Федерациясе Президенты Указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРК «Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте турында” дип исемләнгән Татарстан Республикасы Кануны, 2010 елның 25нче августындагы УП-569 «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендә булган

затларга карата булган таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр бәрелеше, низагларны хәл итү буенча комиссияләр турында” дип исемләнгән Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә **б о е р ы к бирәм**:

1. Беркетелгән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтен башкарган затларның эш тәртипләренә карата булган таләпләрнең үтәлеше һәм мәнфәгатьләр бәрелеше, низагларны хәл итү буенча комиссия турында нигезләмәне расларга.

2. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик хезмәт секторына, дәүләт теркәве уздыру өчен, әлеге Боерыкны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юлларга.

3. Эш башкару һәм тикшерү секторына, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң, әлеге Боерыкны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгының барлык структур бүлекчәләренә җиткерергә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **Д.И.Фаттахов**

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре министрлыгы
боерыгы нигезендә расланды
14.12.2018 №195

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның тәртипләренә карата булган таләпләрнең үтәлү һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү комиссиясе турында

НИГЕЗЛӘМӘ

I. Гомуми нигезләр

1.1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның тәртипләренә карата булган таләпләрнең үтәлү һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү комиссиясе турында нигезләмә (моннан соң – нигезләмә)2004 елның 27нче июлендәге 79нчы номерлы ФК «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» дип исемләнгән Федераль канун, 2008 елның 25нче декабрендәге 273нче номерлы ФК «Коррупциягә каршылык күрсәтү турында» дип исемләнгән Федераль канун, 2010 елның 1нче иблендәге 821нче номерлы «Федераль дәүләт хезмәтендәге затларның тәртипләренә карата таләпләрне үтәлүе һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү комиссиясе турында» дип исемләнгән Россия Федерациясе Президенты Указы, 2003 елның 16нче гыйнварындагы 3-ТРК «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы кануны, 2010 елның 25нче августындагы УП-569 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендәге затларның тәртипләренә карата таләпләрне үтәлүе һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү комиссиясе турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә эшләнгән. Нигезләмә Татарстан

Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендәге затларның тәртипләренә карата таләпләрне үтәлүе һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү комиссиясен (моннан соң – Комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлеген билгели.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль кануннар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы кануннары, Россия Федерациясе Президенты актлары һәм Россия Федерациясе хөкүмәте актлары, Татарстан Республикасы һәм Министрлар кабинеты актлары, әлеге Нигезләмә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (моннан соң – министрлык) актлары нигезендә алып бара.

1.3. Комиссиянең төп бурычлары – түбәндәге өлкәләрдә ярдәм күрсәтү:

а) Министрлыктагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның (моннан соң – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны булдырмауга юнәлтелгән чикләүләрне, тыюларны, таләпләрне үтәве, 2008 елның 25нче декабрендәге 273-ФК «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль канунда, башка федераль кануннарда күрсәтелгән теләпләрне (моннан соң – эштәге тәртипкә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү) үтвәенә ярдәм итү;

б) Министрлыкта ришвәтчелеккә каршы чаралар күрүдә ярдәм итү.

1.4. Комиссия, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан эшкә алына яки вазыйфасыннан азат ителә торган дәүләт хезмәтендәге затлардан тыш, Министрлыктагы гражданлык хезмәтендәге затлар, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасындагы затларга (моннан соң – дәүләт хезмәте вазыйфасы) карата кулланылган эштәге тәртипкә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү белән бәйле мәсьәләләрне карый.

1.5. Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан эшкә алына яки вазыйфасыннан азат ителә торган дәүләт хезмәтендәге затларның эштәге тәртипләренә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү белән бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты

Аппаратында оешкан Эштәге тәртипкә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаять, административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне кабул итми, эш дисциплинасын бозу факты буенча тикшерү эшләре алып бармый.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Министрлык боерыгы нигезендә билгеләнә. Комиссия составына Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры (моннан соң – министр) тарафынанна билгеләнә торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Министрлыкта дәүләт хезмәте башкара торган Комиссия әгъзалары, сәркатип, комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары да бертигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Коммия составына түбәндәге затлар керә:

а) Министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның кадрлар бүлегенең җаваплы заты, коррупцион хокук бозулар һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат (Комиссия сәркатибе), дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик хезмәт бүлеге, Министрлыкның министр тарафыннан билгеләнә торган бүлекләре хезммәткәрләре.

б) Татарстан Республикасы Президенты эшләр идарәсенең коррупциягә каршы көрәш сәясәте вәкиле һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләсе бүлеге вәкиле;

в) эшләре дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкилләре.

2.3. Министр, 2005 елның 14нче октябрендәге 103-ТРК «Татарстан Республикасы Җәмгыять советы турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы кануны 22.1 маддәсе нигезендә, Министрлык каршында

оешкан җәмгыять советы вәкилен Комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктының «б» һәм «в» өлшеләрендә һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына, министр мөрәҗәгате буенча, тиешле органнар һәм оешмалар белән килешү нигезендә кабул ителгән шартлар үтәлгәндә кабул ителәләр. Килешү, мөрәҗәгать килеп ирешкәннән соң, 10 көн дәвамында карала.

2.5. Министрлыкта дәүләт хезмәтен башкармый торган Комиссия әгъзалары саны Комиссиядәге әгъзаларның гомуми санының дүрттән бер өлешеннән дә ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссиядә кабул ителгән карарларга зыян салырга мөмкин булган мәнфәгатьләр каршылыгы булмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәшләшү хокукына түбәндәге затлар ия:

а) эш тәртибенә карата булган таләпләрнең үтәлү-үтәлмәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын башкара торган ике дәүләт хезмәткәре. Әлеге ике хезмәкәрнең вазыйфалары Комиссия утырышында эше карала торган дәүләт хезмәткәренеке белән бертөрле булырга тиеш;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын башкара торган башка дәүләт хезмәткәрләре; Комиссия тарафыннан карала торган сорауларга һәм дәүләт хезмәте турындагы сорауларга җавап бирә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнары, җирле үзидарә хезмәткәрләре; мәнфәгатьләре туры килә торган оешма вәкилләре; Комиссия утырышында эш тәртибенә карата булган таләпләрнең үтәлү-үтәлмәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгы, низагларны көйләү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәре үзе. Соңгысының утырышта катнашу-катнашмавы турында карар Комиссия рәисе карары нигезендә һәр конкрет очракта Комиссия утырышына кадәр, ким дигәндә, өч көн алдан, дәүләт хезмәткәренең үз ходатайствосы нигезендә кабул ителә.

2.8. Комиссия утырышында барлык әгъзалар санының, ким дигәндә, өчтән ике өлеше булса, Комиссия утырышы һәм аның карарлары канунлы санала. Министрлыкта дәүләт хезмәте башкаручы затлар катнашында гына Комиссия утырышы уздыру мөмкин түгел.

2.9. Комиссия әгъзасының көн тәртибенә куелган мәсьәләне хәл итәргә комачаулый торган, мәнфәгатьләр каршылыгынә китерергә мөмкин булган берәр мәсьәлә барлыкка килгәндә, Комиссия утырышы башланганчы, бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта әлеге Комиссия әгъзасы көн тәртибенә чыгарылган мәсьәләне хәл итүдә катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышы уздыру өчен нигез:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокук актлары нигезендә уздырылган тикшерү (эш тәртибенә карата булган таләпләрнең үтәлүенә кагылышлы мәсьәләдә материалларны дәүләт хезмәткәрләре тапшыра) нәтиҗәсендә, министрның, дәүләт хезмәткәренең, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфасына дәгъва кылучы затның 2009 елның 30нчы декабрендәге УП-702нче номерлы Татарстан Республикасы Президенты указы тарафыннан расланган һәм тапшырылырга тиешле керем, милек һәм милеккә кагылышлы бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең керем, чыгым, милек һәм милеккә кагылышлы бурычлар турында дөреслеккә туры килмәгән яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыруы турында, гражданлык хезмәткәрләренең эш тәртипләреһәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү мәсьәләсендә таләпләрне үтәмәве мәгълүмат бирүе;

б) Министрлыкның кадрлар бүлегенең Җаваплы заты исеме, ришвәтчелек һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эшләре өчен Җаваплы зат исеменә Министрлык боерыгы нигезендә расланган тәртиптә түбәндәге затлардан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләр:

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждannar хезмәте исемлегенә кергән, шул вазыйфаны биләгән очракта, Министрлык боерыгы нигезендә, керем, чыгым, милек һәм милеккә бәйле бурычлар, тормыш иптәшләре, балигъ булмаган балаларының керем, чыгым, милек һәм милеккә бәйле бурычлары турында мәгълүмат тапшырырга тиеш булган, дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкаручы заттан коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмаларда вазыйфа биләүгә, яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмаларда граждannar белән хокукый килешү төзү нигезендә хезмәт башкарырга ризалык;

дәүләт хезмәткәренең, объектив сәбәпләргә бәйле рәвештә, тормыш иптәшенең, балигъ булмагана балаларының керем, милек һәм милеккә бәйле бурычлары турында мәгълүмат тапшыра алмавы турында гариза;

дәүләт хезмәткәренең 2013 елның 7нче маеннан булган 79нчы номерлы Фк «Аерым категория затларга Россия Федерациясе чикләреннән читтә булган чит ил банкларында исәп (кертем) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс документларына ия булуны һәм (яки) эш йөртүне тыю турында» дип исемләнгән Федераль канунны, чит ил органнары тарафыннан кулга алыну, идарә итүне тыю сәбәпле үти алмау турында гариза;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаны башкарганда барлыкка килгән шәхси мәнфәгатьләр (мәнфәгатьләр каршылыгынә, низагка китергән яки китерергә мөмкин булган мәнфәгатьләр) турында хәбәр бирүе;

в) министр тарафыннан дәүләт хезмәткәренең, 2012 елның 3нче декабреннән булган 230нчы номерлы ФК «Дәүләт вазифаларын биләүче һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольләү турында» дип исемләнгән Федераль канунның 3нче маддәсенең 1нче өлешендә каралган таләпләрне үтәмичә, дөреслеккә туры килмәгән яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыруын дәлилли торган тикшерү материаллары тапшырылу;

г) 2008 елның 25нче декабреннән булган 273нче номерлы ФК «Коррупциягә каршы көрәш турында» дип исемләнгән Федераль канунның 12нче матдәсенең 4нче өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1

маддәсе нигезендә, коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларның Министрлыкта дәүләт хезмәтен башкаручы затлар белән килешү, билгеле бер эш башкару өчен хезмәт яки гражданлык хокук килешүе төзүе турында Министрлыкка кабул ителгән хәбәрләр. Дәүләт хезмәткәренә Комиссия тарафыннан мондый төр килешүләр төзү тыелган булып, Министрлыкта эшләү дәверендә әлеге оешманың кайбер дәүләт идарәсе функцияләре хезмәт бурычлары булып саналырга яки мондый төр гражданнарга коммерциячел яки коммерөиясез оешмаларда вазыйфа биләү, яки билгеле-бер хезмәт башкаруга рөхсәт алу мәсьәләсе Комиссия тарафыннан каралмавы шарты белән.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» өлешенең икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгать, Министрлыкта дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкара торган зат тарафыннан Министрлыкның кадрлар хезмәте бүлегенең Җаваплы затына, Ришвәтчелек һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эшләре өчен Җаваплы затка тапшырыла.

Мөрәҗәгатьтә затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы, яшәү урыны, дәүләт хезмәтеннән азат ителгәнчегә кадәр соңгы ике елда башкарган вазыйфасы, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманы атамасы, эшләү өлкәсе, вазыйфаның бурычлары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе функцияләре, килешү төре (хезмәт килешүе яки гражданлык хокук килешүе), килешү гамәлдә булган срок, килешү нигезендә башкарылган хезмәт өчен түләү күләме күрсәтелә.

Министрлыкның кадрлар хезмәте бүлегенең җаваплы заты, Ришвәтчелек һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эшләре өчен җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгать карала. Шуның нәтиҗәсендә мөрәҗәгатьнең төп асылы нигезендә, 2008 елның 25нче декабреннән булган 273нче номерлы ФК «Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында» дип исемләнгән Федераль канунның 12нче маддәсе таләпләре буенча, йомгак ясала.

3.3.Әлеге нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» өлешенең икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә җыенган дәүләт

хезмәткәре тарафыннан бирелә ала һәм әлеге Нигезләмә таләпләре буенча Министрлык тарафыннан каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «г» пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать, Министрлыкта дәүләт хезмәте башкарган затның 2008 елның 25нче декабрендәге 273нче номерлы ФК «Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында» дип исемләнгән Федераль канун таләпләрен үтәве турында мотивлашкан нәтиҗә ясый торган Министрлыкның кадрлар хезмәте бүлегенең җаваплы заты, Ришвәтчелек һәм башка төр хокук бозуны профилактикалау эшләре өчен җаваплы заты тарафыннан карала.

3.4.1. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пункының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәр Министрлыктагы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазифаи заты тарафыннан карап тикшерелә, ул хәбәрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерли.

3.4.2. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктындагы бишенче абзацында һәм «д» пунктында күрсәтелгән хәбәрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләгәндә Министрлыкның кадрлар хезмәтенең вазифаи затлары мөрәҗәгатьне яки хәбәрне җиткергән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә һәм аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы, ә моның өчен махсус вәкаләт алган министр яки министрның урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрә ала. Мөрәҗәгать яки хәбәр, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки хәбәр кергән көннән алып җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки хәбәр, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки хәбәр кергән көннән башлап 45 көн дәвамында тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән артмаган срокка озынайтылырга мөмкин.

3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4.1 пунктларында каралган мотивлашкан нәтиҗә түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

а) Әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктының «д» өлешендә һәм «б» пунктының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм хәбәрләрдә искә алынган мәгълүмат;

б) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мәнфәгатьләре булган оешмалардан, рәсми соратып алу нигезендә алынган мәгълүмат;

в) Әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктының «д» өлешендә һәм «б» пунктының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм хәбәрләрдә искә алынган мәгълүмат нигезендә ясалган мотивлашкан нәтиҗә, шулай ук әлеге нигезләмәнең 3.13, 3.15, 3.18нче пунктлары нигезендә бер карарга килү өчен тәкъдимнәр.

3.5. Министрлык боерыгында каралган тәртиптә Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алучы мәгълүмат килеп ирешкәндә, Комиссия рәисе:

а) 10 көнлек срокта Комиссия утырышы көнен билгели. Шушы Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, Комиссия утырышының көне күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән башлап 20 көнгә соңга калып билгеләнә алмый;

б) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны Министрлыкның кадрлар хезмәте вазифаи затына килеп ирешкән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктының «б» пунктында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турында үтенечнамәләрне карап тикшерә, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карап тикшерү турында (карап тикшерүдән баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карап тикшерү буенча Комиссия утырышы керемнәр, милек һәм милеккә карата бурычлар турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән вакыт узган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.7. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктында күрсәтелгән хәбәр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карап тикшерелә.

3.8. Комиссия утырышы аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәре яки дәүләт органында дәүләт хезмәте вазифасын биләгән граждан катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында дәүләт хезмәткәре яки граждан шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пункты нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт хезмәткәреннән яки гражданнан башка үткәрелә:

а) әгәр Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрдә дәүләт хезмәткәренең яки гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәсә;

б) Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән, тиешле тәртиптә аның үткәрелү вакыты һәм урыны турында хәбәр алган дәүләт хезмәткәре яки затлар Комиссия утырышына килмәсәләр.

3.9. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яки Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән затның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка кертелгән мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карап тикшерелә.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

3.11. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан 2009 елның 30 декабрендәге № ПУ-702 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан

Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Нигезләмә нигезендә тапшырылган, әлеге пунктның «а» пунктында аталган белешмәләрнең ышанычсыз һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.12. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлешен билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәвен билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлмәвенә юл куелмаска тиешлеген күрсәтергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.13. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирү;

б) гражданга, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирмәү һәм бу рөхсәт бирмәүне нигезләү.

3.14. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив һәм хөрмәткә лаек дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан качу ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.15. дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавының сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан качу ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

а) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» Федераль канун таләпләрен үтәү мөмкин булмаган шартларның объектив һәм хөрмәткә лаек булуын танырга;

б) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясе чикләрендә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата акча чараларын һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкин булмаган шартларның объектив булмавын һәм нигезсез булуын танырга. Бу очракта министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.15.1. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктсының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазифаи вәкаләтләр үтәлгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазифаи вәкаләтләр үтәлгәндә шәхси кызыксынучанлыкның мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки алар барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.16. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «в» пунктсында каралган мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карарларның берсен кабул итә.

3.17. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «г» пунктсында каралган мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында» Федераль законның 3нчы маддәсенең 1нче өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларның ышанычлы һәм тулы булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә контрольлек итү хакында» Федераль законның 3 маддәсенең 1нче өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларның ышанычсыз һәм тулы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту барышында алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки), аларның компетенцияләре кысаларында, башка дәүләт органнарына җибәрергә киңәш итә.

3.18. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» пунктсында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аның тарафыннан, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүгә яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылуга рөхсәт бирергә;

б) аның тарафыннан коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазифаи биләүнең яки коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкарылу (хезмәтләр күрсәтүнең) 2008 елның 25нче декабрендәге 273нче номерлы ФК «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12нче маддәсендәге таләпләрне боза

дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга күрсәтелгән шартлар турында прокуратура органнарына һәм хәбәр итүче оешмага җиткерү турында киңәш итә.

3.19 Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а, «б», «г», «д» пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия шушы Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында күрсәтелгәннәрдән аермалы карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен Министрлыкның норматив-хокукый актлары проектлары, министрның карарлары яки әмернамәләре әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә карап тикшерү өчен министрга тапшырыла.

3.21. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары (әгәр Комиссия башкача карар кабул итмәсә) утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән, яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны Комиссиянең утырышында катнашкан әгъзалары имзалый. Комиссия карарлары, шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктсының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерүдән кала, министр өчен киңәш итү рәвешендә була. Шушы Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктсының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри рәвешле була.

3.23. В Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының көне, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелүче дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының

исемен, вазифасын күрсәтеп, Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең тәгъбирләнеше;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелгән дәгъвалар, аларны нигезли торган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылына карата аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка килү көне;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.24. Комиссиянең карары белән риза булмаган әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә беркетелергә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш көненнән соң 7 көнлек срокта министрга, тулысынча яки аннан өземтә рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга җибәрелә.

3.26. Комиссия утырышы беркетмәсен карап тикшерергә бурычлы һәм үз компетенциясе кысаларында дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул иткәндә һәм коррупциягә каршы көрәш оештыруның башка төрле мәсьәләләре буенча андагы киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия киңәшләрен карап тикшерү һәм кабул ителгән карар турында министр язмача рәвештә аңа Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң бер айлык срокта Комиссиягә хәбәр итә. Министрның карары Комиссиянең якын киләчәктәге утырышында игълан ителә һәм фикер алышуларсыз гына игътибарга алына.

3.27. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп билгеләре ачыкланган очракта, бу хактагы мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында мәсьәләне хәл итү өчен, министрга тапшырыла.

3.28. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләрен яки җинаять составын үз эченә алучы гамәлләрне кылуы (гамәл кылмавы) ачыкланган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылыну (гамәл кылынмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый очракны раслый торган документларны 3 көнлек срокта, ә кирәк булганда – кичекмәстән, хокук кулланучы органнарга тапшырырга бурычлы.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан алынган өземтә аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карап тикшерелгән дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

3.30. Комиссия карарыннан алынган, Комиссия сәркатибенең имзасы һәм Министрлык мөһере белән таныкланган өземтә аңа карата Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктсының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә карап тикшерелгән, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазифасын биләгән гражданга имзалатып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча, Комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, белдерүнамә белән заказлы хат итеп җибәрелә.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документаль яктан тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырыш көне, вакыты һәм үткәрү урыны турында хәбәр итү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен тапшырыла торган материаллар белән таныштыру Министрлыктагы кадрлар хезмәтенең коррупция һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазифаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.